**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дала Зәе торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2023 елның 19 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлегенең Дала Зәе торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Дала Зәе торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге Дала Зәе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, сугыш һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

Дала Зәе Зәй бистәсе территориясендә территорияне төзекләндерүне оештыру һәм яшелләндерү( чишмәне төзекләндерү)

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Дала Зәе урамындагы юлларны карап тоту (чокыр ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин урамы, 5 йорт, Подлесныйавылы, Үзәк урам 50 йорт (авыл мәдәният йорты) адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы